**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет**
**Сарлинского сельского поселения**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Центральная, д.68А, с. Сарлы,
423315
Тел. 365-34

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**Сарлы авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

Үзәк урам, 68А,
Сарлы авылы, 423315
Тел. 365-34

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«06» август 2018 ел №14

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге Советының 2014 елның 23 гыйнварындагы 54-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сары авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү хакында ( 21.11.2014 №70-37, 21.11.2016 №40-24, 04.09.2017 №60-32, 02.07.2018 №99-51 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьялары һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән җитәкчелек иткәндә, 2018 елның 02 августында Сарлы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе бәяләмәсе нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2014 елның 23 гыйнварындагы 54-3 номерлы карары (21.11.2014 № 70-37, 2016 елның 21 ноябрендәге 40-24 номерлы, 04.09.2017 № 60-32, 02.07.2018 № 99-51 карары редакциясендә) белән расланган җирләрдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләүгә түбәндәгеләр керергә:

1.1. 36 статьяга. Шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналары:

Индивидуаль торак йортлар белән торак төзелешенең территориаль зонасы өчен шәһәр төзелеше регламентларына күчемсез милекне файдалануның төп рөхсәт ителгән төрләренә карата җир кишәрлекләренең максималь чик күләмнәрен билгеләү өлешендә үзгәреш кертергә - 5000 кв.м».

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү тәртибен һәм срокларын (1 нче кушымта) билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык М.Р.Шәрипов